**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап (решения/ответы)**
**2021-2022 учебный год**
**11 класс**

**I. Сүзләрнең татарчага тәрҗемәсен языгыз /** Переведите слова на татарский язык (10 баллов. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* ).

Девушка! *(обращение к незамужней девушке)*, знакомство, качество, прощение, терпение, совесть, вера, родословная, мероприятие, паук.

*Туташ!, танышу, сыйфат, кичерү (гафу итү), сабырлык, вөҗдан, иман (ышаныч), шәҗәрә, чара, үрмәкүч.*

**II. *Фонема* һәм *транскрипция* терминнарына билгеләмә бирегез /** Дайте определение терминам *фонема* и *транскрипция* (10 баллов. *За каждый правильно данное определение по 5 баллов).*

*1. Фонема – сүз һәм кушымчаларны төзи, аларны бер-берсеннән аера торган иң кечкенә сөйләм берәмлеге (Фонема – телнең башка кечкенә кисәкләргә бүленми торган аваз берәмлеге, ул сүз һәм аның формаларын аера) – 5 б.*

*2. Транскрипция ул – әйтелештәге бөтен үзенчәлекләрне язуда чагылдыру өчен кулланыла торган фонетик язу системасы (Сөйләмнең аваз составын тулы итеп чагылдыру өчен кулланыла торган махсус язу системасын транскрипция дип атыйлар) – 5 б.*

**III. Сүзләрдәге хаталарны табыгыз һәм дөресләп языгыз /** Найдите ошибки в словах и напишите правильные варианты (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу*).

Утыннык, тоссыз, дулкыннану, күреңгән, комлак, гөмбагыш, сузыңкы, соңго, икеләммичә, баштубән.

*Утынлык, тозсыз, дулкынлану, күренгән, комлык, көнбагыш, сузынкы, соңгы, икеләнмичә, баштүбән.*

**IV. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез** / Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения (15 баллов. За каждое задание по 5 баллов).

Галиәсгар байның подвалында яшәгән ятим малай егет булыр, үзе китаплар яза башлар. (Ә.Фәйзи)

1) Галиәсгар байның подвалында яшәгән ятим малай егет булыр, 2) үзе китаплар яза башлар. (Ә.Фәйзи)

Галиәсгар байның – аергыч

подвалында – урын хәле

яшәгән, ятим – аергычлар, малай – ия, егет булыр – кушма хәбәр, үзе – ия, китаплар – туры тәмамлык, яза башлар – кушма хәбәр.

2. ▭ = ▭

3. Бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, бәйләүче чара – санау интонациясе.

**V. Тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз. /** Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. (10 баллов, по 1 баллу за каждый правильный пример)

Казан **дәүләт** университетына килеп, ике ел ана теле, **милли әдәбият** өлкәсендә **гыйлем** өсти Айнур. Аны безнең татар **дөньясы** төрле яктан кызыксындыра. Болар аның йөрәгендә генә түгел, фотограф-**рәссам** буларак, альбомнарында да урын ала. Үзенең **нәселе** чыккан Сергач якларын, Казан каласын **һәм** дә үзе туган Финляндия илендә яшәүче

**милләттәшләренең гореф, гадәтләрен**, көнкүрешен киногa төшереп, бу фильмнарны Хельсинкиның үзәк телевидениесеннән күрсәтүгә ирешә ул. *(З. Шакирҗан)*

**VI. Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. /** Сделайте морфологический разбор слов в предложении (10 баллов. За каждый правильный ответ по 1 *балла*.).

Тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. *(Ә. Еники)*

Тургай – исем сүз төркеме, баш килештә, берлек санда;

сайраганда – исемләшкән сыйфат фигыль, сайра – тамыр, -ган –билгесез үткән заман с.ф.кушымчасы, -да –урын-в.к.куш.;

җир – исем сүз төркеме, баш килештә, берлек санда;;

өстенә – бәйлек сүз, тамыры – өст-, 3 зат б.с. тартым белән төрләнгән, юн.к.-дә.

җиңелчә – рәвеш, тамыр – җиңел, -ча – рәвеш ясагыч к., күләм-чама рәвеше.

генә – кисәкчә,

уйчан-моңсу – парлы сыйфат, асыл сыйфат.

бер – билгесезлек алм.

тынлык – исем сүз төркеме, ясалма, тын+лык, баш килештә, берлек санда;

җәелә – -ә кушымчалы хәзерге заман хикәя фиг.

**VII. Татар теле буенча дәреслекләр (хезмәтләр) төзегән бер галим турында языгыз. Язмагызда 1) аның турында белгәннәрегезне, 2) хезмәтләренең исеме, 3) бер хезмәтенең эчтәлеге турында кыскача сөйләгез. /** Напишите об одном татарском ученом-языковеде, авторе учебников. В рассказе опишите 1) его деятельность, 2) основные труды, 3) содержание одного из его трудов (15 баллов. Каждый вопрос оценивается 5 *баллами*).

Укучылар 11 нче сыйныф дәреслегендә урын алган тел галимнәре (В. Хаков, М.Зәкиев, Р. Юсупов, Ф. Сафиуллина, Ф. Хисамова һ.б) яки башка галимнәр турында язарга тиеш.

**VIII. «Халыкныкы халыкта саклана. *(Әмирхан Еники)*» канатлы сүзен сез ничек аңлыйсыз? Шушы гыйбарәдә әйтелгән фикергә таянып, 70 сүздән ким булмаган инша языгыз. /«Всё народное хранится в народе» (Амирхан Еники)** Напишите, как вы понимаете данный афоризм? Опираясь на это выражение, напишите сочинение (не менее из 70 слов) (20 баллов).

Әлеге канатлы гыйбарәдә халыкның гасырлар буе тупланып килгән байлыгы – халык авыз иҗаты (фольклор) әсәрләре турында әйтелә. Укучы татар халык мәкальләре, әйтемнәре, җыр-йолалары, гореф-гадәтләре турында язарга тиеш.

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу** | |

| | | |
|---|---|---|
| | **эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |